**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 9** **22.11.2024**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Урсай авыл җирлеге составына керүче
Урсай авылында 2025 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2025 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Боек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә 2 төркем инвалидлар очен 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Урсай авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре күрсәтү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылы торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү,);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урсай торак пунктында юлларны профильләштерү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Урсай авылыныщ Совет урамы буенча (мафлар сатып алу һәм урнаштыру, койма сатып алу һәм урнаштыру , Урсай авылының юлларын кардан чистарту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районыныщ рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге башлыгы З.Х.Рахимьянова

УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ